СОВЕТ МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

07.09.2018 | с. Русское Макулово | 57-231

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы карары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегендә гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017елның 27 сентябрендәге 39-161 номерлы карары нигезендә.

Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проектын 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә һәм аны гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе 2 нче кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе 3 нче кушымта нигезендә.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеген

төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча халык алдында тыңлауларны 2018нче елның 12 нче октябрендә 14.00 сәгатьтә авыл мәдәният йорты бинасында, Рус Макыл авылы, Үзәк урамы, 125 нче йорт адресы буенча уздырырга.

4. Башкарма комитетка Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге халкының кергән тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

5. 2017 елның 10 сентябренә кадәр әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
ТР Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге башлыгы

А. И. Матвеева